Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Баграж-Никольский авыл җирлегенең
Баграж-Никольский торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы карары

11 ноябрь 2021 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, 2021 елның 08 ноябрь 11 сәгать 00 минутта, узган гражданнарның җыен нәтиҗәләре нигезендә “Сез 2022 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Баграж-Никольский авыл җирлегенең Баграж-Никольское авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 400 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм әлеге средстволарны җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү максатыннан түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрү белән килешәсезме: су белән тәэмин итү системасын норматив хәлгә китерү, смета төзү, техник күзәтү үткәрү һәм җирлек милкенә рәсмиләштерү өчен?» гражданнар җыены беркетмәсе төзелде

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 41 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 37 кеше, бу 90 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

гражданнар җыенында катнашучыларның 31-е «РИЗА» позициясе өчен тавыш бирде;

гражданнар җыенында катнашучыларның 6-е «КАРШЫ» позициясе өчен тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Баграж-Никольский авыл җирлегенең Баграж-Никольский торак пунктында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - чынбарлыкка туры килә.

2.Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Баграж-Никольский авыл җирлегенең Баграж-Никольский авылында яшәү урыны буенча теркәлгән, даими яшәүче булган һәр балигъ булган кешедән үзара салым средстволарын 2022 елда 400 сум күләмендә кертергә.

3. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү: су белән тәэмин итү системасын норматив хәлгә китерү, сметалар төзү өчен түлә, техник күзәтчелек үткәрү һәм җирлек милкенә рәсмиләштерү.

4. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетысында бастырырга, Баграж-Никольский авылы, Үзәк урам, 31б йорты территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә, «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU), Әлмәт муниципаль районы сайты «Интернет» челтәрендә урнаштырырга.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына керту өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче Н.М. Новиков